Бүгенге санда



Күзге ярминкә Өлкәннәр декадасына старт бирде. 2 бит.


# Дуслык
Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе
30 сентябрь 2015 ел
№ 71 (10600)


**1 октябрьгә һава торышы:** аз болытлы һава, җил төньяктан, 4 м/с; температура көндез +13°С, төнлә +6°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ
Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

### ГРАНТЛАРГА ИСӘП ТОТАБЫЗ

Кичә "ТатРИТЭКнефть" ТППсы делегациясе Татарстан Республикасында "РИТЭК" ААҖнең социаль һәм мәдәни проектлары конкурсына йомгак ясау чарасында катнашты. Җиңүчеләрне котлау тантанасы Казанның "Пирамида" комплексында үтте. Татарстанлылардан конкурска 700 проект кергән, шуларның 22се – нурлатлылардан.

### МАШИНАЛЫ БУЛДЫЛАР

Дүшәмбе көнне районның дәүләт ветеринария берләшмәсе "Лада Ларгус" машинасына ия булды. Машина ачкычларын берләшмә җитәкчесе Василий Лысовка Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов республика Президенты исеменнән тапшырды. Бу көнне республиканың ветеринария службаларына 34 шундый автомобиль бүләк ителде.

### СУ СЫЙФАТЫН ЯХШЫРТУ КИРӘК

Район торак пунктларында су сыйфатын тикшерделәр. Роспотребнадзор Идарәсенең территориаль бүлегеннән хәбәр итүләренчә, чаралар Госстрой һәм РФ Хөкүмәте йөкләмәсе буенча үткәрелгән. Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, район башкарма комитетына суның сыйфатын яхшырту буенча чаралар үткәрү өчен материаллар җибәрелгән.

### МӨСЕЛМАННАР ФОРУМДА

Мөселман мәгариф оешмалары укытучыларының Халыкара форумында районның дин белгечләре дә катнашты. Чара Казанда 29–30 сентябрьдә узды. Анда Марокко, Һиндстан, Гарәп Әмирлекләреннән дә дин белгечләре катнашкан.

**2016 ЕЛНЫҢ 1 ЯРТЫЕЛЛЫГЫНА РАЙОН ГАЗЕТАСЫНА ӘБУНӘ ДӘВАМ ИТӘ**
*БЕЗ СЕЗНЕ ПОЧТАДА ҺӘМ РЕДАКЦИЯДӘ КӨТӘБЕЗ.*

# ХӘРӘКӘТТӘ - БӘРӘКӘТ




СТАРТКА БЕРЕНЧЕ БУЛЫП МӘКТӘП УКУЧЫЛАРЫ БАСТЫ

**Традиция буенча, ел саен үткәрелүче "Милләтләр кроссы" җиңел атлетика стартына быел 3320 нурлатлы басты.**

Массакүләм йөгерү чарасы Нурлатта зур спорт бәйрәме булып узды. Теләүчеләр өчен ГТО нормаларын тапшыру мөмкинлеге дә тудырылды, концерт программасы һәм кайнар чәй тәкъдим ителде. Стартка басарга вакыт шактый булуга карамастан, аэропорт территориясе халык белән тулы иде. Һава торышы да спорт сөючеләр яклы булды, җәйне хәтерләтте, иртән үк кояш чыкты.

Кросска җыелучыларны район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин сәламләде. Ул катнашучыларның елдан – ел арта баруына шатлануын белдерде. Сөенми мөмкин дә түгел, һөнәрмәннәр генә түгел, старт сызыгына басучылар арасында кече яшьтәге балалар белән өлкәннәр дә килгәннәр иде.

– Бүген зур спорт бәйрәме, биредә оттыручылар юк, – диде район башкарма комитеты җитәкчесе уңышлы старт һәм җиңел финиш теләп. Әсхәт Касыймович үз чыгышында район оешма – предприятие җитәкчеләренең, авыл җирлекләре башлыкларының спортка битараф калуына борчылуын да җиткерде. Бу көнне VIP узышларга чыккан 200гә якын җитәкче нигездә мәгариф һәм мәдәният тармагы хезмәткәрләре иде.

Спортчыларга район башлыгы Равил Кузюровның сәламнәрен район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова җиткерде. Спорт бәйрәмендә әлеге тармакта республика, район күләмендә уңышларга ирешкән командаларны, мәктәп укучыларын билгеләп үттеләр.

Беренче булып старт сызыгына мәктәп укучылары басты. Аннан соң муниципалитет, төрле тармак хезмәткәрләре, укытучылар спорт белән дус булуларын күрсәттеләр. Гаиләләре белән йөгерүчеләр дә бар иде. Балалар бакчаларына йөрүче сабыйлар да эти – әниләреннән калырга теләмәде. Йөгерү физик көч, чыныкканлык таләп итсә дә, беркем дә арымады, финишка килгәндә дә йөзләрдән шат елмаю югалмаган иде.

– Мондый кросста беренче генә йөгермибез, - диләр гимназиянең 9нчы сыйныфында укучы Григорий һәм Михаил Алексашкиннар. – Спорт белән махсус шөгыльләнәбез, без – малайларга чыныгу өчен ул аеруча кирәк. Ә быелгы нәтиҗәләр – үз дистанциябездә 1,2 урыннарга ирешүебез өчен әтиебезгә рәхмәтлебез, ул безнең тренерыбыз булды.

– Төп максатым беренче килү түгел иде, – ди VIP узышларда 2 нче урынны яулаган район мәгариф бүлеге җитәкчесе Линар Маняпов. – Үземнең формада булуымны сынау, укучыларга һәм коллегаларга үрнәк күрсәтер өчен йөгердем.

– Финишка җитәрәк бераз тын кысыла башлады-башлавын, – ди Түбән Чаллыдан пенсионер Анатолий Елаков. – Аннан барысы да нормальләште. Сәламәт яшәү өчен хәрәкәтләнергә, физик күнегүләр ясарга кирәк дип саныйм.

Спорт бәйрәмендә 5 дистанциядә барлыгы 80 призлы урын яуланды.

**Зилия ӘКСАНОВА**

УНКӨНЛЕК

# Өлкәннәрне игътибар көтә

**Нурлатта Өлкәннәр ункөнлеге пәнҗешәмбе, 1 октябрьдә шәһәр Мәдәният сараенда бәйрәм концерты, спорт–масса чаралары белән ачылачак.**

**1–10 октябрьдә** участок, район үзәк хастаханәләрендә чираттан тыш медицина каралулары үтәчәк, табиблар бригадалары ерак авылларга чыгачак. Бу чорда өлкәннәр өчен мунча хезмәтләре график буенча (график газетаның 4нче битендә) бушлай, 50 процент ташлама белән чәчтараш хезмәтләре күрсәтеләчәк. Ункөнлек барышында "Гармония" халыкка социаль ярдәм күрсәтү үзәгендә патронатта торучылар өчен "Җылы тәрәзәләр", "Чиста ишегалды" акцияләре оештырылачак.

**3 октябрьдә** Балалар сәнгать мәктәбендә район мәдәният йортының "Ветеран" халык хоры иҗади кич утырырга чакыра. 6 октябрьдә үзәк китапханәдә тематик кичә узачак. Нурлат картлар һәм өлкәннәр интернат-йортында хәйрия концерты, район, авыл мәдәният йортларында, клубларында бәйрәмнәр үтәчәк. **1–15 октябрьдә** шәһәр һәм район мәдәният йортларында кинофильмнар күрсәтү каралган, Кама аръягы һәм Нурлат тарихы төбәк музеенда бу чорда өлкәннәр өчен экскурсияләр булачак. **2 октябрьдә** Кама аръягы һәм Нурлат тарихы төбәк музеенда "Зирәклек" хатын – кызлар клубы утырышы узачак. Шахмат – шашка сөюче өлкәннәрне **3 октябрьдә** Балалар – үсмерләр спорт мәктәбендә турнирга көтеп калалар.

Ункөнлек барышында оешма – предприятиеләрдә, авыл җирлекләрендә, хуҗалыкларда пенсионерларны хөрмәтләүгә багышланган чаралар планлаштырыла.

**Зилия ӘКСАНОВА әзерләде**

**ШАЛТЫРАТЫГЫЗ!**

**Ункөнлек дәвамында социаль хезмәт һәм халыкка дәүләт социаль ярдәме күрсәтү буенча "кайнар линия" эшләячәк. Сорауларны 2–06–55, 2–92–09, 2–06–56 телефоннары аша юлларга мөмкин.**

ФЕРМЕР ХУҖАЛЫКЛА

# Үз җирең өчен җавап та тот

**Узган атнада район башлыгы Равил Кузюров район фермерлары белән җир мәсьәләсе буенча җитди сөйләшү уздырды. Очрашуга авыл җирлекләре башлыклары да чакырылган иде.**

Бүгенге көндә райондагы барлык сөрү җирләренең 3,7 проценты – ә бу 3118 гектар – вак фермер хуҗалыкларына туры килә. Районның беренче фермерларыннан саналучы Ильяс ага Тямаевның, мәсәлән, шәһәр янәшәсендә үк 60 гектарлап җире бар. Фермер үз җирендә печән, печән орлыгы һәм сабан культуралары игү белән шөгыльләнә. Әмма җәйнең коры килүе быел сабан культуралары уңышына зур зыян салган.

– Бөртеклеләрдән нибары 8әр центнер уңыш җыеп алдым, – ди Ильяс ага. – Шуңа да киләсе елдан бары люцерна игүгә генә күчәрмен, ахрысы. Гомумән, вак фермер хуҗалыгына үз җиреңне карап тору бик авыр – мәйданнар кечкенә булса да, һәр төр эшне башкару өчен билгеле бер техника, ягулык-майлау материаллары кирәк. Ә алар арзан тормый. Файда алу өчен бик күп тырышырга гына түгел, игенчелекнең серләрен дә белергә кирәк.

Кызганычка каршы, фермер хуҗалыкларының кубесендә вәзгыять шундыйрак. Дәүләттән субсидияләр рәвешендә берникадәр ярдәм күрсәтелеп торса да, җир әлләни уңыш белән сөендерми. Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ислам Сафиуллин әйтүенчә, район буенча уртача уңыш 22,2 центнер булса, фермер хуҗалыкларында нибары – 12,2. Һәм җитәкче моны фермерларның җиргә карата җавапсызлыгы нәтиҗәсе дип тә саный.

– Без райондагы барлык вак фермер хуҗалыклары җирләрен карап, анализ ясап чыктык, – ди идарәнең җитештерү-маркетинг бүлеге начальнигы Фаил Ивандеев. – Кызганычка каршы, фермерларда җиргә караш төрле. Кубесендә орлыкларны яңартуга, чәчү әйләнешенә, ашламалауга игътибар бирелми. Фермерлар нигездә күпьеллык үләннәр игү белән шөгыльләнә, шуңа да без алга таба люцернага күбрәк игътибар бирергә киңәш итәбез. Чөнки бу культураның коры елларда да уңышы яхшы була.

Районның җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе Рәмис Шәйхетдиновның да җир кишәрлекләре хуҗаларына әйтер сүзе җитди иде.

– Җир алгансыз икән, аннан "Фермер хуҗалыклары турында", "Авыл хуҗалыгы багланышындагы җирләрнең әйләнеше турындагы" законнар таләпләрен истә тотып файдаланыгыз. Җирдән максатчан файдаланмаган яки җир законнарын истә тотмаган өчен күләмле штрафлар яный, – дип мөраҗәгать итте ул һәм районда җир хуҗаларына бәйле күңелсез очракларны мисалга китерде, законнарның нечкәлекләрен аңлатты.

Киңәшмәгә йомгакны район башлыгы Равил Кузюров үзе ясады.


– Районда фермер хуҗалыкларының составы начар түгел. Әмма үз җаваплылыгызга җир алгансыз икән, аны тиешенчә, игенчелек культуралы таләпләренә җавап бирерлек итеп карап та торырга кирәк. Махсус комиссия булдырып, 1 ноябрьдән һәр фермердан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә үз җиреңдә башкарылган барлык эшләр буенча хисап тотуны гамәлгә кертәчәкбез. Алга таба сорау күпкә кырысрак булачак, – диде ул.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

КИСӘТҮ

# Бәрәңгегә авыру яный

**"Бакчаларда быел бәрәңге гомер булмаганны ишелеп уңды", - дип сөенгән нурлатлыларның кайберләре бу көннәрдә борчуга төште – алган бәрәңгеләр чери башлаган, ди.**



"ЮЕШ ЧЕРЕК" АВЫРУЛЫ БӘРӘҢГЕ

– Якушкино, Гәйтән авылларыннан бәрәңге чери дип мөраҗәгать итүчеләр булды, - ди Россельхознадзорның Нурлат идарәсе дәүләт инспекторы Николай Ларионов. – Бәрәңгеләр тышкы яктан исән кебек, әмма бармак белән баскач, йомшак икәне сизелә, эчке ягы исә көрән төстә. Авыру бәрәңге үрнәкләрен Казандагы "Татар төбәкара ветеринария лабораториясе" ФГБУсына җибәреп тикшерттек һәм аннан "юеш черек" авыруы дигән җавап алдык. Кызганычка каршы, районның башка авылларында да бар мондый бәрәңгеләр.

"Юеш черек" (икенче төрле атамасы "сулы черек") бәрәңге эссе һавада үскәндә, уңышны җыеп алганнан соң барлыкка килә икән. Күрәсең, быел бакчаларда бу авыруның таралуына җәйге эссе көннәр җирлек биргән. Авыру бәрәңге төссезләнә һәм йомшара, ә эчке ягы көрән төскә керә.

– Авыруның таралуына юл куймас өчен бәрәңгене базларга салганчы яхшылап карап, тикшереп чыгарга, черек бәрәңгеләрне аерырга кирәк. Чөнки авыру бәрәңгеләр бар уңышны юк итәргә мөмкин. Әгәр базларга салырга өлгергәнсез икән, әле соң түгел, бар уңышны яхшылап карагыз, кирәк икән, чыгарып яңадан чүпләгез, - дип кисәтә дәүләт инспекторы.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

## Тагы бер чишмә барлыкка килде

**Ике–Иске һәм Яңа Әмзә авыллары арасындагы Ташлы елга башында кайчандыр чишмә челтерәп утыруын күпләр оныткан да булгандыр инде.**

Ә менә Иске Әмзәдән Ирек Нәбиуллин онытмаган, һәм алай гына да түгел, чишмәгә яңа гомер бирергә булган. Иске чишмәне чистарту, тирәсен тоту, өстенә капкачын ясау кебек мәшәкатьләрне ул бер дә иренмичә башкарган да Гает бәйрәме алдыннан ике авылның да өлкәннәрен чишмә янына чакырып зур булмаган бәйрәм дә ясап алган.

–Көн бик матур иде, рәхәтләнеп чәен дә эчтек, коймактан да авыз иттек, балачактан өйрәнгән шигырьләребезне дә искә төшердек,–дип шалтыраттылар безгә хәбәрчеләребез Сания Фәтхетдинова белән Вәсилә Минапова. Ә Ирек Нәибуллинның исә беренче генә игелекле гамәле түгел инде бу. Иске Әмзә авылы чишмәсен тәртипкә китереп карап торучы да, беренче сыйныфка баручы сабыйларга бүләкләр өләшүче дә – ул, авылда кемгәдер борчу-кайгы килсә дә иң беренче булып ул ярдәмгә ашыга.

– Шуңа тормышлары бөтен, йортларында бәрәкәт, балалары тәүфыйклы һәм бәхетле дә аларның, – диләр авылдашлары әлегә гаилә башлыгына рәхмәт укып.

Сәкинә НУРУЛЛИНА

ҮЗМӘШГУЛЬЛЕК

# Бар да тырышлык белән килә

**Фома авылыннан Мансур һәм Гөлҗиһан Җәлалетдиновлар бу җәйдә көн саен дәүләткә 82 литрга кадәр сөт тапшырганнар. Моннан тыш, продукцияләре әле үзләренә каймак, эремчек, май ясарга да җитеп бара.**

Хәзер исә сөт күләме кимегән. Әмма, сезонга бәйле рәвештә, бу хәл бөтен җирдә дә күзәтелә бит. Хуҗалыклары кечкенә түгел – 6 савым сыер, 2 тана, 2 үгез һәм 6 бозаулары бар. Бу бит әле эре мал гына. Хуҗалыкта терлек азыгы әзерләүдә беренче ярдәмче – атлары да бар. Ә кош-кортның исәбе-хисабы юк.

– Терлекчелектә генә түгел, теләсә кайсы тармакта уңышка ирешү өчен ялкауланмаска гына кирәк, – ди гаилә башлыгы.

Һәм аның белән килешми мөмкин түгел. Бөтен мал-туарны ашатып-эчертергә, абзарны чистартырга, җитәрлек терлек азыгы әзерләргә кирәк булганда ялкауланып кара! Әле бит өйдә һәм бакчада да эшләр җитәрлек. Ирле-хатынлы Җәлалетдиновлар "Сәләйманов Ә.И." КФХсында хезмәт куялар. Гаилә башлыгы элеватордагы мастерскойны җитәкли, ә Гөлҗиһан төрле эшләр башкара. Һәр буш вакыттан файдаланып, кышкылыкка бик күп терлек азыгы да әзерләп калганнар, 32 төргәк салам, 6-7 тонна печән запасы бар. Бер өлешен болыннан чапканнар, өй янындагы участокларыннан сезонга ике тапкыр люцерна да җыеп алганнар.

Җәлалетдиновларның гаилә эшләрен башлаганда өч сыерлары гына була. Аларны халыкның үзмәшгульлеге программасы буенча бүлеп бирелгән акчага сатып алганнар. Беренче капиталны максатчан куллану билгеле бер вакыттан соң аларга терлекләрнең баш санын арттырырга мөмкинлек бирә. Продукцияне иртән һәм кичен сөт җыючыларга тапшыралар. Гаилә бюджетына кергән өстәмә акчаларны да максатчан кулланалар. Чыгымнардан калган акчаны башка терлек азыгы сатып алырга, биналарны ремонтлауга тоталар. Кызларына да ярдәм итәргә кирәк. Юлия һәм Гөлия Самарада һөнәри белем алалар. Каникуллар вакытында әти-әниләренең иң төп ярдәмчеләре алар. Шундый хуҗалыкны алып бару җиңел түгел. Әмма Җәлалетдиновларны, башка күп кенә фомалыларны кебек үк, авыл тормышының авырлыклары куркытмый. Дәүләт тарафыннан терлек-туар тоту өчен бүлеп бирелә торган субсидия дә зур ярдәм булып тора.

– Фома авылында 15 гаилә үз хуҗалыкларында 5тән артык сыер тоталар, - ди авыл җирлеге башлыгы Рәшит Абдрахманов. – Безнең җирлектә терлек азыгы әзерләү авыр – печән чабу өчен болынлыклар аз. Шуңа да карамастан, кешеләр тырышалар. Гомуми көтүлектә 360 баш эре мөгезле терлек йөри, шуларның 213е – савым сыерлар.



Автор фотосы

ҖӘЛАЛЕТДИНОВЛАР ЭШНЕ БЕРГӘЛӘП БАШКАРЫРГА КҮНЕККӘН

Маргарита ЛИТТА

# КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Фома авылында яшәүче **Фәһимә Хәсәнгата кызы ГАЛИМОВАГА** 1 октябрьдә 65 яшь тула. Кадерле туганыбыз, туган көнең белән ихлас котлыйбыз! Сиңа кайгы-хәсрәтсез тигез тормыш, озын гомер, нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы,ак бәхетләр телибез.

Һәр яңа көн бәхет алып килсен,
Алсу таңнар күмсен шатлыкка,
Яшәү дәрте янсын йөрәгеңдә,
Картаерга бер дә ашыкма.

**Иң изге теләкләр белән: Идрисовлар, Мөхәммәтшиннар, Сәгыйровлар, Яруллиннар гаиләләре.**

Кадерле тормыш иптәшем, әниебез, әбиебез **Рәмзия Гариф кызы Рәҗәпованы** 55 яшьлек юбилее белән ихлас күңелдән котлыйбыз. Туар таңнарың тыныч, саулыгың ныклы, гомерең бәхетле булсын! Авырмый, кайгы-хәсрәт күрми озын гомер итүеңне, балаларыңның, якыннарыңның игелеген күреп яшәвеңне телибез. Туачак таңнарың һәрвакыт нурлы, күк йөзең һәрвакыт аяз булсын.

Иң кадерле, газиз кешебез син,
Бу буш сүзләр диеп уйлама.
Әниләргә сыенып яшәгәннәр
Бәхетен таба якты дөньяда.
Ходай сиңа
сәламәтлек бирсен,
Син булганда өебез нур чәчә.
Киңәшчебез, терәгебез булып
Яшә әле, яшә йөзгәчә.

**Сине яратып тормыш иптәшең Вахит, кызларың Гөлназ, Динә, кияүләрең Рамил, Ильмир, оныкларың Эльвина, Альмир, Дамир.**

Якты Күл авылында яшәүче кызыбыз, сеңлебез, апабыз **Рәмзия Гариф кызы Рәҗәпованың** 1 октябрьдә олы юбилее – аңа 55 яшь тула. Без аңа ныклы исәнлек, җан тынычлыгы, гаилә иминлеге телибез. Алга таба да балалар, оныклар куанычын, туганнар җылысын һәм гаилә кайгыртуын тоеп яшәргә язсын.

Сөйкемле карашың кояшка тиң,
Бар тормышны нурга күмәсең,
Бу дөньяның
барлык хикмәтләрен
Бары тик син генә беләсең.
Тормышта гел ярдәм итеп тора
Зирәк киңәшләрең, җылы сүзең.
Иркәлисең, яратасың, юатасың,
Тыңлыйсың да,
аңлыйсың да үзең.
Сәламәтлек, озын гомер язсын,
Гел көләч һәм
яшь бул хәзергәчә.
Күңелең синең
күтәренке булсын,
Сөенеп һәм сөендереп
мең-мең яшә.

**Иң изге теләкләр белән әти-әнием, абыйларың, энең, сеңлең һәм аларның гаиләләре.**


## ТРЕБУЮТСЯ

*водители с личным авто для работы в такси. Т. 8-937-620-01-48.
*в связи с расширением производства ЗАО «Техсервис» специалист со знанием гранд-смет (высшее образование, опыт работы), электромонтер. Т. 2-05-74.


**Центр. Аптека № 94** (г. Нурлат, ул. Гагарина, д. 10)
**5 октября с 14.00 до 15.00 ч.**
"РАДУГА ЗВУКОВ"
ВЫСТАВКА-ПРОДАЖА
**СЛУХОВЫЕ АППАРАТЫ**
(заушные, карманные)
НЕ ТРЕБУЕТСЯ СПЕЦИАЛЬНАЯ ПОДГОТОВКА
Цена: от **6900** до **11500** руб. **ГАРАНТИЯ**
**ЦИФРОВЫЕ** (пр-ва Дании, Германии, России )
Цена: от **12800** до **15500** руб. **Товар сертифицирован.**
**Справки и заявки на дом**
по тел: **8-901-866-81-57**
Сдайте один старый аппарат и получите скидку при покупке нового 7%.*
*Полную информацию об организации акции, правилах проведения, сроках, месте можно узнать по адресу и телефону.
ОГРН 304183133700096 от 31.03. 2003 г., ИП Вилков В.А., ИНН 183100561312.
РЕКЛАМА
**ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА**

**ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА «KRAUSS»***
С 1 января по 31 декабря 2015 г. при заказе 5 окон, 6-е в подарок*
Деревенские окна по 2000 руб.
Откосы, подоконники, москитные сетки.
Работаем по всему Татарстану.
Рассрочка без % (предоставляет ИП Ахметов Ф.Ф.).
*подробности по т.: 8-9274-000-606, 8-9272-449-000.
ИП Ахметов Ф.Ф. *КРАУСС реклама

**В Н И М А Н И Е !!!**
**Только с 1 по 30 сентября 2015 г.**
Компания "Оконные системы"




**Окно 1300x1400**
Подоконник 300 мм
Отлив 150мм
Монтаж с демонтажем
При заказе более 2-х окон:
**П О Д А Р О К** до **1000р с окна***

| Rehau | KBE | Montblanc | Exprof |
|---|---|---|---|
| 7700руб | 7200руб | 6500руб | **6000**руб |

т. **8-927-742-66-67, 8-908-383-89-98**
*Подробности по указанным телефонам. Организатор: ООО "СВК". Реклама

с 1 по 30 октября 2015 г.
в салоне «ДОКТОР ОПТИКА»
специальное предложение для пожилых людей:
при заказе очков скидка 25% на очковые линзы!*
г. Нурлат, ул. Советская, д. 120, тел.: 2-17-88, 8-927-427-79-27;
ул. Гиматдинова, д. 81, тел.: 8(84345) 2-91-99, 8-937-610-69-30;
ТЦ «Радуга», тел. 8-937-613-99-88.
Лиц. № 16-01-000675 от 13.12.2007 г.
Имеются противопоказания.
Необходима консультация специалиста.
Реклама

**ОЦМП «Классик»**
*реализует*
*ПРОФНАСТИЛ оцинкованный, окрашенный, под искуственный камень, под дерево.*
*Гладкий лист. С-8, С-10, Сс-10, СШ-10, МП-20, С-21, НС-35, НС-44.*
*Металлочерепица:*
*- «Супермонтерей»*
*- «Каскад»*
*- «Классик»*
Сайдинг металлический:
- «Корабельная доска»
- «Блок-хаус»
- «Софит»
- под дерево.
Доборные элементы, водосточная система.
Евроштакетник.
**ВСЕГДА НИЗКИЕ ЦЕНЫ!**
**Наш адрес: г.Нурлат ул. Заводская, 1А, напротив ЖБИ**
**Т.: (884345)2-54-00, 8-9276-778-776.**
Реклама

**УВАЖАЕМЫЕ ПЕДАГОГИ И РОДИТЕЛИ!**
**Республиканский центр «Черноморец» предлагает детский отдых в детском оздоровительном лагере «Зорька» круглогодичного проживания (Неклиновский район, с. Дмитриадовка, Ростовская область). Приблизительная стоимость путевки с проездом на 10 дней – от 11 тыс.руб. Педагоги набравшие группу (15 человек) выезжают бесплатно. По всем вопросам обращаться по т.: 8(843) 2939052, 2932498.**

**ООО «Перспектива»**
**1. Продает.**
**2. Сдает в аренду.**
**3. Сдает в аренду с последующим выкупом помещение под магазин или офис (недорого), расположенный по адресу: ул. Садовая, 1Б.**
**Цена договорная.**
**Справки по т.: 2-58-21, 2-58-24, по адресу: г. Нурлат, ул. Заводская, 1.**

**ПЕНОИЗОЛ.**
**УТЕПЛЯЕМ СТЕНЫ, ПОТОЛКИ жидким пенопластом**
**8-937-600-33-02, 8-987-233-33-18.**

**ООО «Перспектива»**
**1. Продает. 2. Сдает в аренду. 3. Сдает в аренду с последующим выкупом готовый объект:** животноводческая ферма на 24 единицы КРС (недорого), расположенного по адресу: д. Бурметьево, ул. Нижняя, 1. Цена договорная. Справки по т.: 2-58-21, 2-58-24, по адресу: г. Нурлат, ул. Заводская, 1.

**БЛОКИ 20*20*40**
**с доставкой от 39 р.**
**89277128965,**
**8(846)9228965 - Камиль.**

**3 октября в поликлинике ЦРБ ведут прием специалисты МДЦ г.Казань**
**по следующим направлениям:**
**эндокринология**
**неврология**
**кардиология**
**сосудистая хирургия (с аппаратурой).**
**Врачи проведут исследования на высокотехнологичном оборудовании.**
**Т. 8-917-269-54-27.**
**Имеются противопоказания.**
**Необходима консультация специалиста.**
Реклама

**ПОСТУПЛЕНИЕ НОВОГО ТОВАРА НА СТАРОМ ВЕЩЕВОМ РЫНКЕ**

**В консультативно-диагностическом центре «Саулык», г. Нурлат, ул. Жемчужная, 25, ведут прием специалисты из г. Казани по следующим направлениям:**

**3 ОКТЯБРЯ 2015 года**
1. Гастроэнтерология.
2. Терапия, кардиология, ревматология.
3. Взрослая, подростковая гинекология.
4. Неврология.
5. Сосудистая хирургия, новый революционный метод при варикозной болезни вен, не требующий госпитализации и наркоза. Помощь при сосудистых звездочках.
6. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследования сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное доплеровское картирование), исследования сосудов головного мозга, верхних и нижних конечностей.

**4 ОКТЯБРЯ 2015 года**
1. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии, ведение беременности.
2. Диетология.
3. Педиатрия-кардиология.
4. Отоларингология.
5. Урология. Помощь при эректильной дисфункции, ЗППП, мужском бесплодии, хр.простатите, аденоме предстательной железы.
6. Врачи проведут исследования органов малого таза, плода на 1,2 и 3 триместрах.

**10 ОКТЯБРЯ 2015 года**
1. Онкогинекология-эндокринология, специалтзация по менопаузе.
2. Терапия, кардиология, ревматология.
3. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследования сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное доплеровское картирование).

**11 ОКТЯБРЯ 2015 года**
1. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии, ведение беременности.
2. Диетология.
3. Эндокринология.
4. Педиатрия-кардиология.
5. Врачи проведут исследования органов малого таза, плода на 1,2 и 3 триместрах.

Справки и предварительная запись по т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.
ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г. ОГРН 1021605358103.
**Имеются противопоказания.**
**Необходима консультация специалиста.**
Реклама


**РАСПИСАНИЕ ОКАЗАНИЯ УСЛУГ БАНИ ПЕНСИОНЕРАМ В ДЕКАДУ ПОЖИЛЫХ ЛЮДЕЙ ПО НУРЛАТСКОМУ МУНИЦИПАЛЬНОМУ РАЙОНУ 2015 ГОДА**

**Городская баня МУП, ул. Советская, 177:**
**Четверг (01.10.2015г.)** – *мужской день*
**Среда (07.10.2015г.)** – *женский день*
**График работы с 12.00 до 19.00.**

**Мини оздоровительный комбинат, ул. Куйбышева, 21:**
**Пятница (02.10.2015г.)** – *женский день*
**Вторник (06.10.2015г.)** – *мужской день*
**График работы с 12.00 до 22.00.**

**Центральная городская баня, ул. Спортивная, 7:**
**Четверг (01.10.2015г.), суббота (03.10.2015г.)**
**– мужской день** *(по 20 человек)*
**Пятница (02.10.2015г.), воскресенье (04.10.2015г.)**
**– женский день** *(по 20 человек)*
**График работы с 12.00 до 19.00.**

**Сауна-бассейн, ул. Тельмана, 32а**
**Среда (07.10.2015г.)** – *женский день*
*График работы с 11.00 до 19.00.*


**ПЛАКАТЫ, ОТКРЫТКИ, РАСТЯЖКИ «С ДНЕМ УЧИТЕЛЯ!» В МАГАЗИНЕ «КАРАНДАШ» (УЛ. ГИМАТДИНОВА, 52, ЦЕНТР).**

**2 ОКТЯБРЯ в здании типографии,**
*ул. К.Маркса, 19*
**состоится выставка-продажа пальто, курток ОСЕНЬ-ЗИМА**
*(Москва, Белоруссия).*
**Кредит предоставляет АО «Альфа-Банк».**
Реклама



**Гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" АҖ** www.tatmedia.ru www.nurlat-tat.ru

"Дуслык" ("Дружба", "Туслах") газетасы
Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

"Татмедиа" АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир С.Н. Хәйруллина
Тел.: 2-36-14

**Редакциянең адресы:**
423040, ТР, Нурлат шәһәре, К.Маркс ур., 19
**Электрон адрес:** e-mail: redak@list.ru
**Телефоннар:** 2-36-12 – җаваплы сәркатип, реклама бүлеге, факс
2-36-20 – рус бүлеге
2-36-13 - корреспондентлар
2-25-88 – бухгалтерия

**Нәшер итүче:**
"ТАТМЕДИА" АҖ 420097, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2.

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы (Татарстан) идарәсе тарафыннан 2013 елның 16 маенда теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы: ПИ № ТУ 16-01018
Бу сан "Татмедиа" АҖ филиалы "Идел – Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды
Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2.
Басуга тапшыру вакыты:
график буенча – 14.30,
фактта – 14.30

Тираж - 1643

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булып чыгарга мөмкинлеге юк.
**Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
Реклама белдерүләренең төгәллеге өчен реклама бирүче үзе җаваплы.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Газета **чәршәмбе** һәм **җомга** чыга.
Заказ №5981
Язылу индексы – 16185
Бәясе ирекле.

12+


© Язмаларны күчереп бастыру редакциянең язмача рөхсәте белән генә мөмкин.

ЙОЛАЛАРЫБЫЗ

# Корбан чалу Аллаһыга якынайта

**Үткән пәнҗешәмбе көнне районның барлык мәчетләрендә мөселманнар ислам диненең иң бөек бәйрәмнәренең берсе – Корбан гаетен билгеләп үттеләр.**




РАЙОН МӨСЕЛМАННАРЫ КОРБАН ГАЕТЕН МӘЧЕТЛӘРДӘ КАРШЫ АЛДЫ

Шәһәрнең базар яны мәчетендә узган бәйрәм намазында Нурлат муниципаль районы башлыгы Равил Кузюров барлык мөселманнарга изге теләкләрен җиткерде. Гает намазы укылды, вәгазь сөйләнде. Олы йоланы үтәгән мөселманнарның күбесен бәйрәмнең янә бер саваплы эше берләштерде – бәйрәм көнне Аллаһы Тәгалә хөрмәтенә корбан чалу йолалары узды.

Нурлатлы Зариповлар гаиләсендә йола буенча Корбан бәйрәме иң зур дини бәйрәм булып уза. Әлеге гаилә борынгы йолаларны үтәп, динебезгә хөрмәт белән яши. Иртән-иртүк гаиләдә бәйрәм рухы хөкем сөрә: гаилә башлыгы Галимҗан абый мәчеткә гает намазына ашыга, тормыш иптәше Гөлнур апа бәйрәм табыны әзерләү белән мәшгуль. Традиция буенча, бу көнне гает намазы укылгач, Аллаһы ризалыгы өчен корбаннар чалып, игелекле гамәлләр кылу шарт. Быел да Зариповлар өч корбан чалырга карар кылганнар. Гаиләдәге өч хатын-кыз – әниләре, кызлары һәм оныкларының исәнлегенә багышларга булганнар аларны.

– Корбан чалу – кешеләр өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнгән, пәйгамбәрләр кылган һәм безгә кушып калдырылган изге гыйбадәтләрнең берсе ул, – ди гаилә башлыгы. – Бу көн кылган гөнаһларыбызның ярлыкануы, Аллаһ кушмаган гамәлләрдән тыелу, үзеңә һәм әйләнә-тирәдәгеләреңә, фәкыйрьләргә, ятимнәргә шатлык бүләк итү көне буларак бик тә кадерле.

Корбанга чалына торган хайваннарны Зариповлар бер атна элек сатып алганнар.

– Корбанга пар тояклы мал - кәҗә, сарык, дөя яки сыер сайларга кирәк, – ди район мөхтәсибе урынбасары Абдулла хәзрәт Мортазин Корбан чалуның нечкәлекләренә тукталып. – Шулай ук авыру хайваннарны корбанга чалу дөрес түгел. Яшенә килгәндә, дөягә - биш яшь, үгез яки сыерга – ике, кәҗә, сарык малына бер яшь булу шарт. Тик шунысын истән чыгармаска кирәк: сарык һәм кәҗә бер кеше өчен генә корбан кылына, ә сыер яки дөя - җидешәр кеше өчен. Шулай ук бер үзеңә бер сыер, бер дөя Корбан кылу да хата түгел. Андый ук мөмкинчелеге булмаган кешеләргә бөтен гаиләгә бер корбан чалырга да ярый.

Зариповлар гаиләсендә дини бәйрәм аш мәҗлесе белән дәвам итә. Мәҗлестә Корбан атаучыларның исәнлегенә догалар укыла, вәгазьләр сөйләнә.

– Аллаһының илчесе Мөхәммәт галәйһиссәләм: "Ашагыз, ашатыгыз һәм саклагыз" дип аңлаткан, – ди хуҗабикә Гөлнур апа. – Шуңа да итне өч өлешкә бүлү хәерле. Өчтән берен бәйрәм табыны әзерләргә, икенче өлешен туганнарга һәм мохтаҗларга өләшергә, калганын үз гаиләңә тотарга диелгән.

Абдулла хәзрәт Мортазин Корбан чалу тәртипләренә тукталып үтте.

– Еш кына Корбан чалганда, янәшәдә аның хуҗасы булу шартмы дип сорыйлар. Пәйгамбәребез кызы Фатыйманың корбанлык хайванын чалганда, аны янына чакыра. Шулай булгач, хуҗаның булуы яхшы, ләкин мәҗбүри түгел.

**– Әгәр кеше тиешле көннәрдә корбан чалып өлгермәсә нишләргә?**

– Матди мөмкинчелегеләге булып та, вакытында суя алмый калса, сарык сатып алырлык акчасын сәдака итеп мескеннәргә бирер. Ләкин ул корбаннан булмас.

**– Шәһәрдә һәм районда санитария таләпләрен үтәү максатыннан махсус урыннар булдырылганмы?**

– Корбан чалу изге бер гыйбадәт, шуңа чалынган малның эч-башлары, тире-тояклары аунап яту матур күренеш түгел. Кызганычка каршы, әлеге максатларда корбан чалуның махсус урыны юк әлегә. Бу эшләрне мәчет территорияләрендә башкарырга мөмкин.

Бәйрәм көннәрендә корбан ите һәм бүләкләр тарату туганлык җепләренең ныгуы һәм күршеләр арасында яхшы мөгамәләләр урнашуга сәбәп була. Аллаһ Тәгалә ризалыгы өчен чалынган корбаннарыбыз кабул булсын иде.

**Зилия ӘКСАНОВА**

ЭКСТРЕМИЗМГА – ЮК!

**23 сентябрьдә Халыклар дуслыгы йортында "Экстремизмга – юк!" айлыгына багышланган киночара үткәрелде. Анда прокуратура һәм полиция вәкилләре, шулай ук 3нче мәктәпнең 6, 7, 8 сыйныф укучылары катнашты.**

# Кино татулыкка өнди

"Тынычлык агачы" дип исемләнгән нәфис фильм аудиториядә зур кызыксыну уятты. Башкача булуы мөмкин дә түгел, чөнки сюжет бик мавыктыргыч.

Төрле миллəттән булган ике дус кыз әти-әниләре белән бергә Ураза һәм Раштуа бәйрәмнәрен каршы алу турында хыялланалар. Әмма бәйрәм көннәре якынлаша барган саен, ата-аналар тарафыннан каршылыклар туа тора, сәбәбе – имештер, аларның дине өчен чит йолалар һәм аларга теге яки бу диннең билгеле нормалары хас түгел. Ягъни алар өчен бер генә дин бар. Ләкин олыларның төрле каршылыкларына карамастан, кызлар ата-аналарын башка диннәргә, гореф-гадәтләргә карата тыныч һәм толерантлы мөнәсәбәттә булырга кирәклегенә ышандыра алалар.

– Һәр кеше әлеге картинадан гыйбрәт алырга тиеш, – дип, үз тәэсирләре белән уртаклашты "7Б" сыйныфы укучысы Родион Левин. – Мин үзем өчен шуны аңладым: безне төрле милләт бәйрәмнәре берләштерә. Без тынычлыкта һәм татулыкта яшәргә тиешбез.

Родион белән бергә урыс һәм татар балалары укый.

– Әгәр сыйныфташларымның дине башка икән, ни өчен алар белән дус булмаска, мин шуны аңламыйм. Мин барлык диннәргә дә хөрмәт белән карыйм.

Нәкъ менә шушы сүзләр безнең көннәрдә зур әһәмияткә ия дә инде. Без тигезлек, бөтен дөньяда тынычлык, игелеклелек, милләтара мөнәсәбәтләр кебек мөһим төшенчәләрне үз аңыбызга сеңдерергә тиеш. Фильмнан соң барган сөйләшү вакытында прокуратура вәкилләре нәкъ менә шуңа басым ясадылар да инде, аннан соң "Мәдәни үсеш үзәге" МБУсының кино хезмәте күрсәтү бүлеге мөдире Зөлфия Яппарова чыгыш ясады. Нурлат районында мондый проблемаларның булмавы ачыкланды.

– Безнең түгәрәкләрдә төрле милләт балалары шөгыльләнә, һәм без аларны урыс, татар яки чуваш булулары ягыннан аермыйбыз. Безнең өчен алар бертигез, чөнки барысын да дуслык берләштерә, – ди Халыклар дуслыгы йорты директоры Роза Сафина.

Зөлфия Яппарова сүзләренә караганда, "Тынычлык агачы" һәрчак чәчәк өчен, әлеге киночараны шәһәребезнең башка мәктәпләрендә дә күрсәтәчәкләр. Иң мөһиме: ике дус кызның тарихы толерантлыкка өйрәтсен иде.

**Анастасия ГОЛОСОВА**

МӘГАРИФ

## 3нче мәктәп яшь армиячеләре – җиңүче

**"Яшь армиячеләр, алга!" дип аталган хәрби-спорт уеннарының республика этабыннан безнең район вәкилләре II урын белән кайтты.**

– Шәһәрнең 3 урта мәктәбе яшь армиячеләре уеннарда уңышлы чыгыш ясап, бик күп призлы урыннар яуладылар, - ди "Форпост" үзәге җитәкчесе Альберт Садретдинов команда җитәкчесе Юрий Пименевның яшь армиячеләрне яхшы әзерләвен билгеләп. – Команда әгъзасы Полина Әбделманова, Олег Улаев, Иван Гришин берничә спорт төрендә призлы урыннарга ия булдылар. Республиканың сигез районы катнашкан финал ярышларында нурлатлылар 60 метрга йөгерүдә, граната ыргытуда һәм "Ратные страницы истории" дип аталган теоретик әзерлектә лидер булганнар.

**Зилия ӘКСАНОВА**

## Толерантлык дәресе үтте

**Узган атнада Нурлат шәһәре балалар китапханәсендә әкиятләр темасына багышланган толерантлык дәресе үтте.**

Беренче мәктәпнең 2В сыйныфы укучылары китапханәчеләр белән берлектә "Шалкан", "Теремок", "Морозко" халык әкиятләре, шулай ук Сергей Аксаковның "Аленький цветочек» әсәре мисалында игелек, миһербанлык, шәфкатьлелек, сабырлык һәм кичерә белү турында сөйләштеләр. Яшь укучыларның һәрберсе бу хакта үз фикерләре белән уртаклашты, әлеге төшенчәләрне ничек аңлавын сөйләде.

"Бер барыбыз да төрле, без барыбыз да тигез! Төрле булсак та, без барыбыз да кирәк!"- чара ахырында балалар шундый нәтиҗәгә килделәр.

**Маргарита ЛИТТА**

ӘБУНӘ

# "Дуслык"ка язылу уңыш китерде

**Нурлат районара почтамтында "Газетага язылып һәм призлар уйнатуда катнаш" акциясе җиңүчеләрен котладылар.**

Чулпаннан Ислам Галимҗанов, Валентина Мельникова һәм Фәүзия Хәсәнова, Төрнәстән Наталия Горшкова, Аркадий Кержаков, Николай Суханов, Нурлаттан Галина Петрякова дүрт сок сыккыч, ике фен һәм плойкага ия булдылар. Аларның алтысына уңышны "Дуслык"ка әбунә китерде. Бер ел элек үткәрелгән акция шартлары буенча, билгеле бер суммага газетага язылырга һәм анкета тутырырга кирәк була. Нурлатлылар катнашкан категория суммасы 400дән 599,99 сумга кадәр.

– Бәхетемне сынап карарга гына теләгән идем, – дип шатлыгын уртаклашты Николай Суханов. – Гомерем буена лотереяда катнаштым, бәхет елмаймады. Иң зур бүләгем спортлотода уйнап откан 3 сум акча булды. 1971нче елда бу зур акча иде әле.




РАЙОН ГАЗЕТАСЫНА ЯЗЫЛУЧЫЛАР БҮЛӘКЛӘР ОТТЫ

Үзенә чыккан фенны әбунәчебез килененә бүләк итәргә карар кылды. Киләсе ел өчен дә бернинди махсус акцияләрне көтеп тормый, һичшиксез, "Дуслык"ка язылырга вәгъдә бирде.

– Районканы 1976нчы елдан алдырам. Газета ошый, спорт турында укырга яратам, җирле яңалыкларны күзәтеп барам, - дип уртаклашты Николай Суханов.

**Маргарита ЛИТТА**

